# *Абдуллина Роза Хәким кызы*

*Мин, Абдуллина Роза Хәким кызы, 1941 нче елның 21 нче ноябрендә Алексеевский районы Түбән Тигәнәле авылында беренче бала булып туганмын.*

*Бу вакытта әтием сугышта булган инде. Шуңа күрә, мин әниемнең авылында туып- үскәнмен. Ә әтием Биектау районы Зур Битаман авылыннан. Ул безне сугыштан соң гына ат белән килеп алган.*

*Әтием  Хәкимҗан сугыш вакытында разведчик була, мотоцикл белән сугышның гел алгы рәтендә йөри. Безнең янга Тигәнәлегә дә берничә тапкыр кайтып китқән. Мин ул вакытлардагы күп әйберләрне хәтерләмим, әнием сөйләгәннәр генә хәтердә. Сугыштан соң, Битаманга да мотоцикл белән кайта ул.*

*Ул вакытлырда безгә иртәнге йокылар насыйп булмады. Бер вакыт булган вакыйганы искә алып китәсем килә:  ''Иртәнге сәгать 4 тә, йокылы – уяулы, каз куарга барганда, сөртенеп егылдым. Карасам – ипи. Аны куана–куана куеныма салып, кире өйгә йөгердем. Бер кырыен кисеп алып, суыра-суыра гына, кире казлар көтүе көтәргә киткәнем истә.''*

*Мәктәптә 4 класс кына белем ала алдым, аннан фермага эшкә киттем. Хезмәт стажым 12 яшьтән башланды.*

*Минем яшьләргә теләгем шул: тормышыбыз тыныч, балалар исән-сау булсын, шушы муллыктан аермасын.*